| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>КАВЗИЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЭУЖИЯК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                                                 КАРАР
19 декабрь 2025 ел                                                             № 65

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кәүҗияк авыл җирлеге башкарма комитетының бухгалтеры хезмәте өчен түләү шартлары турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Сарман муниципаль районының Кәүҗияк авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. 2025 елның 1 гыйнварыннан Сарман муниципаль районының Кәүҗияк авыл җирлеге башкарма комитеты бухгалтерының вазыйфаи оклады күләмен арттырырга.

2. "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге башкарма комитеты 2024 елның 20 июнендәге 9 нчы карары белән расланган Кәүҗияк авыл җирлеге башкарма комитеты бухгалтерының хезмәт хакы шартлары турында нигезләмәләрне»( 02.11.2024 ел, № 17, 30.04.2025 ел, № 50 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерның вазыйфаи окладын түбәндәге үлчәмнәрдә билгеләнә:

| Вазифасы | 3,5 мең кешегә кадәр |
|---|---|
| | халык саны булган башкарма комитет |
| Баш бухгалтер | - |
| Бухгалтер | 29 000 сум |

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә игълан итәргә.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.